| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2023 г.Лениногорск № 2591

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 18 ноябрендәге 1080 номерлы карары белән расланган Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага бирү, даими (сроксыз) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 492-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 18 ноябрендәге 1080 номерлы карары белән расланган Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага бирү, даими (сроксыз) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче кушымтаның 16 пунктында «әлеге күчемсез милек объектлары тәкъдим ителгән» сүзләрен «дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар арендага бирергә тәкъдим ителгән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны рәсми публикаторда бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасары йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72